ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Большая Красная, 15/9, г. Казань,420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Большая Красная ур., 15/9, Казан ш., 420111

тел/факс. 8 (843) 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 134

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

"13" 07 2020 ел.

2020 елның 1 яртыеллыгы өчен гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә кертелә торган түләү күләмен үзгәртү чикләмәләрен саклау буенча дәүләт торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле нәтиҗәләре турында хисап раслау хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 апрелендәге 400 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә гражданнарның түләү күләмен үзгәртү индексларын формалаштыру нигезләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 26 декабрендәге 1068 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе турында нигезләмә нигезендә боерык бирәм:

1. 2020 елның 1 яртыеллыгы өчен гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә кертелә торган түләү күләмен үзгәртү чикләмәләрен саклау буенча дәүләт торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле нәтиҗәләре турында хисап (кушымтада бирелә) расларга.

2. Торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрнең нигезле булу-булмавын тикшерү бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы"нда (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару өчен юлларга.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары С.В.Заһидуллинага йөкләргә.

Башлык С.А. Крайнов

Кушымта

Татарстан Республикасының
Дәүләт торак инспекциясенең
13.07.2020 № 134
боерыгы белән расланды

**2020 елның 1 яртыеллыгы өчен гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә кертелә торган түләү күләмен үзгәртү чикләмәләрен саклау буенча дәүләт торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле нәтиҗәләре турында хисап**

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 26 декабрендәге 1068 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан дәүләт торак күзәтчелеге һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртү чикләмәләрен саклауга карата лицензия контроле гамәлгә ашырыла.

2020 елның беренче яртыеллыгында үткәрелгән планлы тикшерүләр барышында муниципаль берәмлекләрдә гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индексларын арттыру фактлары (алга таба – чик индекслар) ачыкланмады.

2020 елның беренче яртыеллыгында ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан чик индексларны арттыру фактларының булу-булмавын тикшерү буенча планнан тыш ике тикшерү башланды.

Әлеге тикшерүләр, имин булмаган санитар-эпидемиологик вәзгыятькә, яңа коронавирус йогышы (2019-nCoV) таралуга каршы чаралар күрү зарурлыгына бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 18 мартындагы йөкләмәләрен, Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов күрсәтмәләрен үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм дәүләт катнашындагы оешмаларның хезмәт режимы буенча методик күрсәтмәләренә таянып, ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан 2020 елның 20 мартында туктатып торылды һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыру үзенчәлекләре турында һәм Дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контрольлек органнары тарафыннанюридик затларга һәм шәхси эшкуарларга ел саен уздырыла торган тикшерү планнарын әзерләү кагыйдәләренең 7 пунктына үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 3 апрелендәге 438 номерлы карарының 9 пунктын үтәү максатында аларны уздыруы мөмкинлеге булмау сәбәпле туктатылды.

Шул ук вакытта әлеге тикшерүләр барышында тикшерү субъектлары тарафыннан ТР Дәүләт торак инспекциясенә мәгълүматлар һәм документлар бирелде. Әлеге мәгълүматларны һәм документларны анализлау нәтиҗәсендә ТР Дәүләт торак инспекциясе чик индексларны арттыру фактларын ачыкламады.

Шулай ук 2020 елның беренче яртыеллыгында ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан чик индексларны арттыру фактларына карата ике башлангыч тикшерү үткәрелде, алар барышында ТР Дәүләт торак инспекциясе чик индексларны арттыру фактларын ачыкламады.